РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2019г. г. Альметьевск № 175

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 19 октябрендәге «Әлмәт шәһәрендә җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре турында» 75 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

1996 елның 12 январендәге «Җирләү һәм җирләү эше турында» 8-ФЗ номерлы Федераль законга, Әлмәт шәһәре Уставына туры китерү максатларында

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советының 2012 елның 19 октябрендәге «Әлмәт шәһәрендә җирләү урыннарын карап тоту кагыйдәләре турында» 75 нче номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарга кушымтаның 1 бүлеге 1.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле 1.4.1, 1.4.2, 1.4.3 пунктлары белән тулыландырырга:

«1.4.1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлеге зиратларында күмү урыннары зиратның планировкасы нигезендә билгеләнә.

1.4.2. Зиратлар территорияләрендә үлгәннәрне яки һәлак булганнарны алар диненә туры китереп җирләү өчен аерым участоклар яки секцияләр дә төзелергә мөмкин.

1.4.3. Зиратларда ялгыз каберлекләр, туганнар каберлекләре, мактаулы гражданиннар, хәрбиләр (гомуми) өчен җир участоклары каралырга тиеш.

Зиратларда почетлы күмүләр өчен аерым җир биләмәләре каралырга мөмкин.

Әлмәт муниципаль районы үсешенә һәм чәчәк атуына зур өлеш керткән мәрхүмнәрне күмү өчен махсус җир биләмәләре бирелә.

Зиратларда Бөек Ватан сугышында катнашучыларны, шулай ук коралллы конфликтларда һәлак булганнарны җирләү өчен аерым участоклар оештырылырга мөмкин. Әлеге участокларда җирләү хәрби хәрәкәтләрдә үлгән кешенең катнашуын раслаучы документлар булганда башкарыла».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Әлмәт шәһәр Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Бочкарев Н.А.).

Шәһәр башлыгы Т.Д. Нагуманов

«АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ»